ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 42 һәм 43 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 387-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары С.М. Захарова, С.А. Вострикова, Е.И. Кузьмичева, А.Г. Фомичев тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 42 һәм 43 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 387-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 22 феврале
№ 1858-VI ДС

проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
С.М. Захарова,
С.А. Вострикова,
Е.И. Кузьмичева,
А.Г. Фомичёв
тарафыннан кертелә

**Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 42 һәм 43 статьяларына үзгәрешләр кертү турында**

**1 статья**

Татарстан Республикасы Гаилә кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 12 (II өлеш); 2011, № 9 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш); 2013, № 5, № 7; 2014, № 4, № 6 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 52 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 60 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш); 2021, № 36 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2022, № 83 (I өлеш); Ватаным Татарстан, 2022 елның 28 декабре) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 42 статьяда:

а) бишенче өлештә «баланы күтәрү» сүзләреннән «һәм тудыру» сүзләрен өстәргә, «затлар» сүзеннән соң «, әгәр аларның берсе йә икесе дә баланы күтәрү һәм тудыру турында шартнамә (алга таба – суррогат ана булу турында шартнамә) төзелгән вакытка Россия Федерациясе гражданнары булып торса, яисә баланы күтәрү һәм тудыру турында шартнамә төзелгән вакытка Россия Федерациясе гражданлыгы булган ялгыз хатын» сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле 6 һәм 7 өлешләр өстәргә:

«6. Баланы күтәрү һәм тудыру өчен эмбрионны башка хатынга имплантацияләргә язма рәвештә ризалык бирүче әлеге статьяның бишенче өлешендә күрсәтелгән затлар баланы тудырган хатын (суррогат ана) ризалыгы белән генә, шулай ук Россия Федерациясе Гаилә кодексының 51 статьясындагы 5 пунктында билгеләнгән очракларда баланың ата-анасы булып язылырга мөмкин.

7. Әлеге статьяның бишенче өлешендә күрсәтелгән үзара никахта торучы затлар, бала тууны рәсмиләштерү кенәгәсендә баланың ата-анасы булып язылу вакытына аларның никахлары өзелгән яисә гамәлдә түгел дип танылган булса (ир яисә хатын вафат булган очраклардан тыш), суд карары нигезендә һәм суд әлеге никахны гаилә төзү нияте белән түгел, бары тик суррогат ана булу турындагы шартнамә төзү максатларында гына теркәлгән дип танымаса, баланы тудырган хатын (суррогат ана) ризалыгы белән генә баланың ата-анасы булып язылырга мөмкин. Суд мондый никахлашу нәтиҗәсендә хокуклары бозылган ирнең һәм хатынның (намуслы ир һәм хатын) баланың атасы һәм анасы булып языла алу хокукын таный.»;

2) 43 статьяның 4 өлешендә «ир һәм хатын» сүзләреннән соң «яисә ялгыз хатын» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

1. Әлеге закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 42 статьясындагы 5 – 7 өлешләре нигезләмәләре (әлеге Закон редакциясендә), теркәлгән никах булу, шулай ук потенциаль ата-ананың берсенең йә ялгыз хатынның, йә суррогат ананың Россия Федерациясе гражданлыгы булу турындагы мәҗбүри шарт өлешендә, суррогат ананың 2022 елның 19 декабренә «Россия Федерациясендә гражданнар сәламәтлеген саклау нигезләре турында» 2011 елның 21 ноябрендәге 323-ФЗ номерлы Федераль законның 55 статьясындагы 9 өлешендә күрсәтелгән, потенциаль ата-ана йә ялгыз хатын белән төзелгән шартнамә нигезендә бала күтәрүе йә шундый шартнамә нигезендә бала тудыруы очракларына кагылмый.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 42 һәм 43 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма**

«Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 42 һәм 43 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проекты Татарстан Республикасы Гаилә кодексына «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 19 декабрендәге 538-ФЗ номерлы Федераль законга (алга таба – Федераль закон) туры китерү максатында эшләнде. Әлеге Федераль закон белән Россия Федерациясе Гаилә кодексына һәм кайбер федераль законнарга суррогат ана хезмәтеннән файдаланган очракта бала тууны рәсмиләштерү кенәгәсенә баланың ата-анасы булып язылу мәсьәләләрен төгәлләштерүче үзгәрешләр кертелде.

Аерым алганда, Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 42 статьясындагы 5 өлешенә өстәмә нигезләмә кертелә, аның нигезендә үзара никахта торучы ир һәм хатын яисә ялгыз хатын, Россия Федерациясе гражданлыгы булса, баланың ата-анасы булып язылырга мөмкин. Моннан тыш, закон проектында суррогат ана хезмәтеннән файдаланган затларны суд карары нигезендә баланың ата-анасы дип тану очраклары һәм шартлары билгеләнә.

Яңа нигезләмәләр Федераль закон үз көченә кергән көнгә (2022 елның 19 декабренә) суррогат ананың шартнамә нигезендә бала күтәрүе йә бала тудыруы очракларына кагылмый (закон проектының 2 статьясындагы 2 пункты).

**«Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 42 һәм 43 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы кабул ителүгә бәйле рәвештә үз көчен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 42 һәм 43 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив хокукый актларының үз көчләрен югалтуын тану, аларны туктатып тору, үзгәртү яисә башкаларын кабул итү таләп ителми.

**«Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 42 һәм 43 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына финанс-икътисадый нигезләү**

«Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 42 һәм 43 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.